**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб төзү турында» 2008 елның 12 июлендәге ПУ-324 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 27 ноябрендәге ПУ-615 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-209 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-605 номерлы, 2010 елның 1 февралендәге ПУ-36 номерлы, 2010 елның 20 августындагы ПУ-546 номерлы, 2011 елның 7 февралендәге ПУ-48 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1233 номерлы, 2014 елның 8 ноябрендәге ПУ-1023 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы һәм 2016 елның 13 октябрендәге ПУ-917 номерлы, 2017 елның 20 гыйнварындагы ПУ-39 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2018 елның 3 маендагы ПУ-348 номерлы, 2018 елның 19 декабрендәге ПУ-864 номерлы һәм 2018 елның 28 декабрендәге ПУ-890 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб (алга таба – Штаб) составында:

Штаб составыннан Р.Г. Кантюковны, И.Ә. Фәйзуллинны чыгарырга;

Штаб составына кертергә:

Усманов Рөстәм Ринат улын – «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Шәйдуллин Ирек Имам улын – Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасарын;

Штаб әгъзасы Э.Г. Галиевнең вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «ТГК-16» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

б) Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб турында нигезләмәнең 5.1 пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

филиалның, аны электр энергиясен (куәтен) куллану режимына авариягә бәйле чикләүләр кертү графикларын эшләү буенча тиешле диспетчерлык үзәге заданиесенә кертү максатларында Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең «Электр энергиясен ваклап сату базарларының гамәлдә булуы, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары белән расланган Электр энергиясен куллануны тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү режимы кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән күләмнәр белән чагыштырганда, Татарстан Республикасы территориясендә авариягә бәйле чикләүләрнең гомумиләштерелгән күләмен арттыру турында карарын килештерү;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«филиалның һәм челтәр оешмаларының электр энергиясен (куәтен) куллану буенча расланган режимына авариягә бәйле чикләүләр кертү графикларына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен ваклап сату базарларының гамәлдә булуы, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары белән расланган Электр энергиясен куллануны тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү режимы кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән очракта һәм тәртиптә үзгәрешләр кертү кирәклеге турында карарларын килештерү;»;

өченче – алтынчы абзацларны дүртенче – җиденче абзацлар дип санарга;

җиденче абзацны сигезенче абзац дип санарга һәм аңа «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «, Электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарәсе кагыйдәләре турында» 2004 елның 27 декабрендәге 854 номерлы карары белән расланган Электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарәсе кагыйдәләрендә каралган очракларда,» дигән сүзләр өстәргә;

сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 18 март
№ ПУ-177